РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Тумутукского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана д.62Б
с. Тумутук, Азнакаевский район, 423316
Тел (Факс):(8–85592)34-3-42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

Тельман урамы, йорт 62Б
Тымытык авылы, Азнакай районы,423316
Тел(факс):(8–85592)34-3-42

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 ноябрь 2021 ел № 6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

Билгеләргә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы - барча йортлар, Җәлил урамы барча йортлар, Яшьләр урамы барча йортлар;

2.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Ленин урамы - барча йортлар

3.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты –15 ноябрь 2021 ел 10.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты –15 ноябрь 2021 ел 14.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Күк-Тәкә авылы, Ленина ур. , 40 йорт, күпфункцияле үзәк залы;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 05 ноябрьдән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт;
- сайлау хокукына ия булган Күк-Тәкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Күк-Тәкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Тымытык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентларның 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләп, бер тапкыр түләүне киметүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Күк-Тәкә авылында зират коймаларын ясатып урнаштыру;

-Күк-Тәкә авылының М.Җәлил урамы, Яшьләр урамы зиратларында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман ур., 62Б йорт, Күк-Тәкә авылы, Ленина ур., 40 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Э.Х.Гыйләҗева